**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь 2022 ел** **№ 7**

**«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 24 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Төркәш авылы, Үзәк урамы, 44 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Төркәш авылы, Үзәк урамы, 44 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа зиратны өлешчә киртәләү, капка кую, инвентарь өчен будка төзү (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Кыш көне Төркәш авылы юлларын кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Төркәш авылында урам яктыртуны тәэмин итү (энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы клубы бинасына керә торган янкорма төзү (килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, кирәкле материаллар сатып алу, ташу);

- Видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Спорт мәйданчыгын карап тору (смета төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Чапкыч сатып алу;
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ»»?

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Нырты авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710